ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 2 Иске Урыссу ав. 30 гыйнвар 2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Ютазы район Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кабул иткән очракта:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы челтәре басмасында рәсми бастырып чыгару юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru ( 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштыру турында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: иске Урыссу авылы, Совет

урамы, 16в йорт, административ бина; Байлар авылы, Тукай урамы, 41 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы; Какылы-Күл авылы, Елга урамы, 18А йорт, авыл клубы бинасы; Исмәт тимер юл разъезды бистәсе, Болын урамы, 2 йорт, мәгълүмати стенд; Акса-Күл бистәсе, Урман урамы, 1 йорт, мәгълүмати стенд.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова